**ГЛАВА**
**Иж-Бобьинского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Иж-Бубый авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

08.11.2024 Иж-Бубый авылы № 05

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иж-Бубый авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге Башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын беренче этабын 2024 елның 21 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын икенче этабын 2024 елның 21 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Иж-Бубый авылы 1 нче Колхоз тыкрыгы, 2 нче Колхоз тыкрыгы, Заречная урамы, Колхоз урамы, Урман урамы, Яшьләр урамы, Татарстан урамы, Татарстан тыкрыгы, Хезмәт урамы халкы.

- 2 этап: Иж-Бобья авылының Ижевская урамы, Магистраль урамы, Яр буе урамы, Яңа урамы, Үзәк урамы халкы.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2025 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый авылы территориясендә яшәү урыны буенча

теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1) Иж-Бубый торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү:

зиратлар территориясендә кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган авария хәлендәге һәм коры яшеллекләрне сүтү (кисү) ;

-Иж-Бубый торак пунктында традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймаларны кору өчен материаллар сатып алу һәм башка чыгымнар;

2) Иж-Бубый торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау:

- Иж-Бубый торак пунктында җәяүлеләр күперләрен ремонтлау өчен материаллар сатып алу һәм җәяүлеләр күперләрен ремонтлау өчен башка чыгымнар

3) Иж-Бубый торак пункты территориясен төзекләндерү:

- тракторны тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;

-Иж-Бубый торак пункты территориясен төзекләндерү өчен чыгым материаллары сатып алу һәм башка чыгымнар;

4) Иж-Бубый торак пунктының тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларын ремонтлау:

- лампаларны сатып алу һәм алыштыру;

- урамнарны яктырту буенча башка чыгымнар;

5) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

- вак таш сатып алу һәм юллар салу;

- автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар;

6) Иж-Бубый торак пунктында яшәүчеләргә су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау,

- торак пунктта су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар

7) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү

- электр генераторын сатып алу

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Иж-Бубый авылы, Үзәк урамы,20 йорт, авыл мәдәният йорты бинасы.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Р. Р. Ваһапов